# КАРАР

**Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Сухрау авыл җирлеге составына керүче Кызыл Яр торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

2019 елның 22 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 22 ноябрендә уздырылган «Түбән Кама муниципаль районының Сухрау авыл җирлеге Кызыл Яр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 нче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарны, көндезге уку формасы буенча белеем алучы студентлардан тыш, 200 сум күләмендә 2020 елда үзара салым кертү белән килешәсезме. Әлеге сумманын 50% күләмендә 2 нче төркем инвалидар һәм 80 яшьтән узганнар түли, Һәм алдагы эшләрне башкару буенча кызыл Яр авылында пожар гидранты урнаштыруга

ӘЙЕ ЮК».

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 95 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашучы гражданнар саны 89 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 85 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 4 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Сухрау авыл җирлеге составына керүче Кызыл Яр торак пунктында гражданнар җыенын булган дип, халык җыены нәтиҗәләрен чын дип танырга.

2.«Түбән Кама муниципаль районының Сухрау авыл җирлеге Кызыл Яр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1нче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарны, көндезге уку формасы буенча белеем алучы студентлардан тыш, 200 сум күләмендә 2020 елда үзара салым кертү белән килешәсезме. Әлеге сумманын 50% күләмендә 2 нче төркем инвалидар һәм 80 яшьтән узганнар түли, Һәм алдагы эшләрне башкару буенча кызыл Яр авылында пожар гидранты урнаштыруга

ӘЙЕ ЮК».

Мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Сухрау авыл җирлеге сайтында.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сухрау авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Галимов